20. Khabutdinova, M. M. (2022). *Naki Isanbet kak avtor i chitatel' zhurnala satiry i yumora "Chayan"* [Naki Isanbet as an Author and Reader of the Satire and Humor Magazine "Chayan"]. Modern Humanities Success/Uspekhi gumanitarnykh nauk. No. 9, pp. 12–19. (In Russian)

21. Khabutdinova, M. M. (2022). *Naki Isanbet kak avtor zhurnala "Sanek" ("Вилы")* [Naki Isanbet as an Author of "Sanek" ("Pitchfork") Magazine]. Modern Humanities Success/ Uspekhi gumanitarnykh nauk. No. 9, pp. 52–59. (In Russian)

22. Mustafin, R. (1974). *Naki Isanbetu 75 let: stsenarii radioperedachi* [Naki Isanbet Is 75 Years Old: The Radio Broadcast Script]. Arkhiv pisatelya Naki Isanbeta. Zapis'. 3 p. (In Russian)

23. Isanbet, Yu. (2021). *Stat'ya Naki Isanbeta "Na putyakh stanovleniya tatarskoi muzyki (1923)" kak istochnik nauchnogo kommentirovaniya* [Naki Isanbet's Article "On the Paths of Tatar Music Formation (1923)" as a Source of Scientific Commentary]. Tatarica. No. 2 (17), pp. 141–168. (In Russian)

24. Khabutdinova, M. M. (2023). *Vklad Naki Isanbeta v izuchenie Zolotoi Ordy* [Naki Isanbet's Contribution to the Study of the Golden Horde]. Zolotoordynskoe obozrenie. No.1 (11), pp. 181–201. (In Russian)

25. Zamaletdinov, R., Khabutdinova, M. (2023). *Tvorcheskaya istoriya komedii Naki Isanbeta "Ryzhii chichyan i Chernovolosaya krasavitsa"* [The Creative History of Naki Isanbet's Comedy "The Red-Haired Chichyan and the Black-Haired Beauty"]. Zolotoordynskoe obozrenie. Vol. 11, Is.4, pp. 934–956. (In Russian)

26. Magdiev, M. (1979). *Utte aylar, utte ellar, Sin sazynny uinadyn...* [Months Passed, Years Passed, You Played Your Saz]. 2 p. Yash leninchy. (In Tatar)

27. Poppe, N. (1971). *Tatar khalyk tabyshmaklary, 1970* [Tatar Folk Riddles, 1970]. Cen-Cen-
tral Asiatic Journal: International Periodical for the Lan guages, Literature, History and Archaeology of Central Asia (Wiesbaden), Vol. XV, No. 3. (In Tatar)

28. *Naki Isanbetnen Radyik Yunusovka yazgan khaty* (1983) [Naki Isanbet's Letter to Rafik Yunusov]. Arkhiv Naki Isanbeta. 7 p. Kazan. September 20. Zapis'. (In Tatar)

29. Isanbet, N. (2001). *Tatar miflary* [Tatar Myths]. Miras. No. 3, pp. 17–28. (In Tatar)

---

# НӘКЫЙ ИСӘНБӘТ ҺӘМ ТАТАР ФОЛЬКЛОРИСТИКАСЫ

**Миләүшә Мөхәммәтҗан кызы Хәбетдинова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
mileuscha@mail.ru

Нәкый Исәнбәт (1899–1992)[1] – бөтен дөньяга танылган татар галим-энциклопедисты, мәгърифәтче. Күренекле язучы 1899 елның 29 декабрендә Уфа губернасы Златоуст өязе Морзалар волостеның (хәзерге Башкортстан Республикасының Салават районы) Малаяз авылында туа[2]. Татар халкы тарихында тагын да серлерәк затны табуы кыен. Әгәр фольклорчы, телченең фәнни хезмәтләре тюркологиядә аңа галим-энциклопедист буларак какшамас урын тәэмин итсәләр (М.Бакиров [4], Ф.Ганиев [2, 74–86 б.], М.Госманов [5], М.Мәһдиев, С.Сафуанов, Б.Урманче, М.Хәбетдинова [6] һ.б.), драматургия һәм поэзия әсәрләре, тәрҗемәләре – аның иҗатыннан башка татар әдәбияты тарихын күз алдына да китереп булмаслык язучы-классик буларак таныттылар (А.Әхмәдуллин [7], Г.Арсланов [8], Т.Галиуллин [9], С.Кудаш, Х.Мәхмүтов, Р.Рахмани, Ф.Миңнуллина [10], М.Хәбетдинова [11], Н.Ханзафаров [3], Р.Хаплехәмитов [12], Г.Шамуков [2] һ.б.).

Яшь Нәкыйнең балачагы милли мәгариф системасында җәдидчелек реформасы чорына туры килә. Әнисе Таибә абыстай малайны укырга-язарга өйрәтә һәм дини-дидактик әдәбият белән таныштыра. Шул вакытта әтисе Сираҗетдин мулла ярым җәдидчә булган мәдрәсә ача, анда укыту Казаннан алып кайткан татар әлифбасы буенча туган телдә алып барыла, һәм программага дөньяви предметлар

[1] Нәкый Исәнбәтнең библиографиясен төзүдә язучы үзе, аның хатыны Гөлсем Исәнбәт [1, 53–76 б.], Әбрар Кәримуллин [2, 114–123 б.], Назыйм Ханзафаровлар катнашты [3, 171–191 б.]. Мәкаләнең күләмен арттырмас өчен, шул исәптән әдәбият исемлегендә соңгы елларда чыккан хезмәтләрне генә күрсәтәбез. Галимнең 1914–1982 елларда чыккан хезмәтләрен библиографиясеннән карагыз.

[2] Төрле чыганаклар буенча Нәкый Исәнбәт 1899 елның 5 сентябрендә яки 15 декабрендә, яисә 22 декабрендә, яисә 1899 елның 28 декабрендә, яисә 29 декабрендә туган. Язучының әтисе – мулла Сираҗетдин – улын патша армиясенә чакыруны бер елга кичектерү өчен аның туган көнен күчергән.

да кертелә. Өлкән абыйсы башлангычында яшь Нәкый Рус Малаязы авылындагы рус мәктәбендә укый. Нәкый Исәнбәтнең дөньяга карашы 1905 еллардагы татар матбугаты һәм шәкертләр хәрәкәте йогынтысында формалаша.

Яшь Нәкыйнең иртә ачыкланган таланты аңа «Хәсәния» (Уфа) мәдрәсәсендә (1911–1914) яхшы белем алырга мөмкинлек бирә. Шагыйрь Шәехзадә Бабич (1895–1919) аңа әдәби иҗатка «фатиха» бирә. 1914 елда Сираҗетдин мулла улын Казанга, танылган татар галиме Галимҗан Баруди (1857–1921) янына алып килә. Уфадагы укытучылар, Нәкый Исәнбәт, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен (1914–1916) тәмамлагач, Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) дәрәҗәсендәге галим, мөҗтәһид (югары категорияле мөселман хокук-дин белгече) булыр дип ышаналар.

Шул ук вакытта, Нәкый Исәнбәт үзе язучы булырга хыяллана [13, 28–29 б.]. Мәдрәсә укытучыларының юраулары өлешчә тормышка аша. Уку йортын тәмамлагач, Малаяз мулласының малае, дини карьерадан баш тартып, мәгърифәтче, укытучы, язучы, галим-энциклопедист юлын сайлый. Бик күпләр аның башкарган эшләренең күләменә чын күңелдән сокланып, аның алдында баш ия, әмма уңышларына көнләшеп, күралмаучылар да табыла, шуңа күрә алар даими рәвештә мәгърифәтче-галимне эзәрлекләүне дә оештыралар.

Нәкый Исәнбәт өлешенә шундый берничә кампания туры килә: «Академик эш» (1929–1930), «Җидегән» эше (1931–1962), «Миркәй белән Айсылу» эше (1950 еллар азагында милләтчелектә гаепләү), «Идегәй» дастаны тирәсендәге гауга (1944–1992). Үзенең дошманнары өстеннән җиңүгә ирешкән, намуслы исемен яклый алган, бөтен гомере буена татар җәдидчелегенең мәгърифәтчелек идеяләренә тугрылык саклаган галимнең батырлыгы һәм зирәклеге сокландыра.

Нәкый Исәнбәт туган илебез фольклорына зур өлеш кертә. Аның эшчәнлегенең күләмен дөньядагы хезмәтләренең резонансы буенча бәяләргә мөмкин. Нәкый Исәнбәтнең фольклор текстологиясе буенча хезмәтләре туган илебездә, ватандашларыбыз тарафыннан гына югары бәяләнеп калмады (СССР Язучылар берлегендә фольклор бүлеге җитәкчесе, рус фольклорчысы, әдәбият белгече Ю.М. Соколов (1889–1941); Россия һәм совет тюркологы, Төркиянең төрек теле, әдәбияты, фольклоры һәм тарихы, кырым татарлары этнографиясе буенча белгеч В.А. Гордлевский (1876–1956); тюрколог, телче, алтай телләре белгече У.Ш. Байчура (1923–1996)), чит илләрдә дә танылу алды (мадьяр галиме, тюрколог Ласло Мандоки (Иштван Конгур Мандоки, 1944–1992), совет һәм америка лингвисты, этнограф, алтай телләре, монголияне өйрәнү һәм тюркология буенча белгеч Н.Н. Поппе (1897–1991)).

Нәкый Исәнбәт 1911 елларда, ягъни Габдулла Тукай һәм Каюм Насыйрилар үрнәгендә илһамланып, «Хөсәения» (1911–1913) мәдрәсәсендә укыганда ук, фольклор җыйный башлый. Замандашы Бакый Урманче таныкламасы буенча Нәкый Исәнбәт «Мөхәммәдия» (1913–1916) мәдрәсәсендә, Хуҗа Бәдигыйның (1887–1937) фольклор түгәрәге әгъзасы булганнан соң һөнәри җыю эшчәнлеге күнекмәләрен формалаштыра [13, 11–12 б.]. Киләчәктә күренекле әдәбиятчы, Көнчыгыш белгече Газиз Гобәйдуллин (1887–1937) һәм, икътисадчы карьерасыннан баш тартып, фольклорчы, Казан Көнчыгыш академиясендә (1921-1922) һәм Көнчыгыш педагогия институтында (1922–1930) татар фольклоры һәм төрки-татар әдәбияты укытучысы булуны кулайрак күргән Гали Рәхим (1892–1943) дә шушы түгәрәк әгъзалары була [13, 11–12 б.]. Хуҗа Бәдигыйның фольклорчы булып өлгерүендә Венгрия этнографы, антропологы, фольклорчысы Дьюс Месарошта (1883–1957) «стажировка» узуы зур роль уйный. Хуҗа Бәдигый халык иҗаты әсәрләрен системага салганда, татар фольклорчылыгында беренче тапкыр чагыштыру-тарихи методка таяна.

1916 елда Нәкый Исәнбәт туган ягына әйләнеп кайта, анда ул Нәсибаш авылындагы рус классын тәмамлый. Егет Казанда мәгърифәтчелек идеяләрен пропагандалаучы, талантлы шагыйрь-романтик буларак дан казанырга өлгерә. Югары Кыйгыда кыска вакытлы мөгаллимлек курсларын тәмамлап, Нәкый Исәнбәт Малаязның тирә-як авылларында мөгаллимлек итә башлый, буш вакытында исә әдәби иҗат, җәмәгать эшчәнлеге белән шөгыльләнә һәм фольклор җыя. 1919 елда губернаның 2 айлык гомуми белем бирү-педагогия мөселман мөгаллимлек курсларын тәмамлый. Дусты-көрәштәше Һади Сәгъди (1883–1933) йогынтысында, Нәкый Исәнбәт толстойчылык белән мавыга. Фольклор җыю эшенә үзенең укучыларын һәм хезмәттәшләрен дә тарта [14, 157–158 б.]. Нәкый Исәнбәт даими рәвештә кыска сроклы укытучылык курслары лекторы була, бу аңа үзенең тикшерenү географиясен киңәйтергә мөмкинлек бирә. Галим баштарак фольклорга «тере халык иҗаты» итеп карый (П.В. Киреевский).

Фольклор текстлары белән эшләгәндә, Нәкый Исәнбәт бөтенесен рәттән язып ала. Үзенең фольклорчы буларак эш көннәрен язучы «Бер дәрвишнең юл дәфтәре» (1920) очеркында чагылдыра [13, 320–395 б.]. Галимнең бастырып чыгарылмаган кыр материалларын өйрәнү нигезендә без шундый нәтиҗәгә килдек: Нәкый Исәнбәт, җырлар язып алганда, аларның көнкүрешен, нинди дә булса йолалар белән элемтәсен теркәп барган. Фольклорчы текстның тел үзенчәлекләренә игътибар иткән, теге яки бу диалектны саклап калырга теләп, җирле һәм аңлашылмаган сүзләргә аңлатмалар бирергә тырышкан. Җырда нинди дә булса үзгәрешләрне ачыклау өчен, Нәкый Исәнбәт, тайпылышлар бик аз булса да, бер үк җырны берничә тапкыр язып алырга да иренмәгән. Аларны эшкәрткәндә, вариантларга «чагыштырутәңгәлләштерү» үткәргән: аның «Оры аккан» бәете [15], «Коңгыр бога» дастаны һәм шул исемдәге башкорт җыры [16] хезмәтләре белән танышып, моңа җиңел инанырга мөмкин. Нәкый Исәнбәт чичәнлек феноменын өйрәнүгә дә гаять зур өлеш кертә [17].

Нәкый Исәнбәт 1920 елда Уфа халык мәгарифе институтына укырга керә. Ул елларда аның «анархист», «толстойчы» дигән даны таралган була. Татар мәгърифәтчесе фольклорның тәрбияви потенциалына, аның үзгәртүче көченә чын күңелдән ышана. Нәкый Исәнбәтне толстойчыларның шәхесне үзгәртеп кору идеясе үзенә җәлеп итә.

1921 елда, Уфа халык мәгарифе институтында 1 ел укыганнан соң, Нәкый Исәнбәт, көтмәгәндә, БашНаркомпрос юлламасы буенча Харьков халык мәгарифе институтының 3 курсына күчә. Нәкый Исәнбәт уку һәм яшәү урынын очраклы рәвештә генә алыштырмагандыр, дип уйлыйбыз. Галим Харьковтагы рус фольклоры методологиясе белән якыннанрак танышырга карар иткәндер (Д.К. Зеленин, Г. Кагаров, Н.Ф. Сумцов, Р.С. Данковская һ.б.). Харьков Фәнни җәмгыяте утырышларына дискуссияләрдә катнашу өчен Ю.М. Соколов, Г.С. Виноградов кебек дәрәҗәле галимнәр чакырыла. Фәнни дебатларга студентлар да чакырылган, алар арасында Нәкый Исәнбәт тә булган, ул үзенең озын һәм нәтиҗәле фәнни тормышы дәвамында шушы белемнәргә таянган. 1920 нче елларда фольклористика өчен чагыштырмача уңышлы чор дип санала, чөнки күпмедер күләмдә сүз иреге сакланып калган була. Әлеге еллар – ачык дискуссияләр, яңа фәнни мәктәпләр һәм юнәлешләр, түгәрәкләр барлыкка килү чоры. 1920 елда тикшеренүче Д.К. Зеленин, Г.С. Виноградов, Н.Е. Ончуков һәм башкалар инкыйлабтан соңгы чорда тел һәм фольклор өлкәсендәге тере, актуаль борылыш процессларын күзәтү өчен уңай момент күреп алалар.

1921 елның 21 августында Нәкый Исәнбәт татар секциясендә тәрҗемәчелек эшенә керешә, ягъни Украина партиясе ҮК Секретариаты хезмәткәре була. 2 айдан соң ул кабаттан лекторлык эшенә кайта: 1921 елның 15 ноябреннән 1922 елның 5 февраленә кадәр Украина Наркомпросының Татар секциясендә 6 айлык педагогия курсларында укыта. Килеп туган матди кыенлыклар, Харьков университетында укытуның рус теленнән украин теленә алыштырылуы сәбәпле, Нәкый Исәнбәт Мәскәүгә укырга китә (09.02. – 25.09, 1922). Әмма большевиклар партиясе сафына басудан баш тарту сәбәпле, уку йортыннан чыгарыла. 1923 елның апрелендә Нәкый Исәнбәт кабат укытучылар курсында лекторлык эшенә кайта, 4 нче мәктәпкә (1923–1926), Уфаның Башкорт совет партия мәктәбенә (1925–1926), Сәнгать техникумына (1929–1930) укытучы булып урнаша, шулай ук Алласызлар Берлеге Бюросының Өлкә органы, «Алласыз» («Безбожник») журналының редколлегия әгъзалары буларак, дингә каршы пропаганда алып бара. Бу чорда җирле туган якны өйрәнүчеләр һәм югары уку йортлары өчен күпсанлы методик ярдәмлекләр һәм программалар, теге яки бу рәвешле, сәяси фольклорны һәм аны башкаручыларның социаль карашларын теркәү мөһимлеген билгели. Шушы дулкында 1928 елда Нәкый Исәнбәт «сукыр Фәррах» буларак билгеле әкиятче Ф.Д. Дәүләтшин (1887–1956) белән экспериментал хезмәте [18] һәм заманча фольклор җыентыгын («Әйдә, җырлыйк!: (Революция чорында халык җырлары)») [19] басмага әзерли.

Массаларны идеологик тәрбияләү эшендә совет фольклористикасының гамәли бурычларын язучы-сатирик «Чаян» һәм «Сәнәк» сатирик журналлары битләрендә тормышка ашыра, анда даими рәвештә тәхәллүс астында аның сатирик фольклор образлылыгына нигезләнгән хикәяләре, пародияләре, эпиграммалары, фельетоннары, памфлетлары, телеграммалары, такмаклары пәйда була. Шул елларның сатира иҗатында аның шигъри хикәяләре фольклор, бәет, кыйсса кебек жанрлар белән катлаулы бәйләнешкә керә (Чаг.: «Самогон туенда», «Илаһи бәет,

пикуләески гает», «Корбан кыйссасы» (Тулырак кар: [20], [21]).

1920 еллардан башлап, Нәкый Исәнбәт үзенең язмаларын паспортлаштыра башлый. Кыр экспедицияләре вакытында галим корреспондентның исемен, язылу урынын теркәп бара. Кагыйдә буларак, датасы бөтен коллекцияләргә дә куела. Татар фольклорчысы үз эшендә халык иҗаты әсәрләрен татарлар күпләп яшәгән тирәлеккә фронталь язып беркетү ысулын куллана. Болар барысы да бер максатны күздә тота – халкыбызның тормышын һәм аның сәнгати мәдәниятен мөмкин кадәр тулырак чагылдыру. Фольклорчы материалны халык арасында гына җыеп калмый, ә борынгы кульязмалардан да чүпли.

Нәкый Исәнбәт халык җырларының сәнгати һәм тел үзенчәлекләрен бик нечкә тоемлый. Халыкның җыр шигърияте аның өчен үз әсәрләрен тудырырга рухландыручы табигый азык була. 1910–1920 елларда Нәкый Исәнбәт талантлы җырчы-шагыйрь буларак дан казана: «Су-сылу» (1916), «Тугай җыры» (1916), «Су анасы җыры» (1922), «Эңгер җыры» (1922), «Уракчы кызы» (1922), «Син сазыңны уйнадың» (1925). Аның барлык җырлары халык күңеленә үтеп керә. Рафаэль Мостафин (1931–2001) фикеренчә, әлеге җырларның популярлык чыганагы язучының үз халкына якынлыгында, аның шигъри фикерләү үзенчәлекләре һәм белем алуга омтылышында [22]. Татар халык җырларын күзәтеп баруы һәм профессиональ милли музыканы үстерү перспективалары хакында галим күп кенә мәкаләләрендә бәян итә. (*Кар*.: [23]) Галимнең архивында «Татар музыкасы энциклопедиясе»нең тәмамланмаган кульязмалары саклана. «Бер татар авылының моннан йөз ел элек язылган җыр-көйләре», 1966 дигән мәкаләсендә галим үзенең халык җырларын текстологик эшкәртү принциплары белән уртаклаша.

1926 елда Нәкый Исәнбәт «Исламның дөньяга карашлары нигезе» дигән китап бастырып чыгара. Бу – галимнең ислам турында, шул исәптән, мөселман мифологиясе, мәдәнияттә ислам компоненты буенча мәгълүматларны системалаштыручы беренче тәҗрибәсе.

Нәкый Исәнбәт дастаннар, риваятьләр, ягъни классик фольклор әсәрләре белән кызыксына, аларның котылгысыз юкка чыгуын алдан күрә. 1928 елда, җирле белгеч буларак, Нәкый Исәнбәт СССР ФА Башкорт комплекслы экспедициясе (БКЭ АН СССР) эшләренә җәлеп ителә, аның составына 17 экспедиция отряды кертелә. Экспедиция эшләре барышында Нәкый Исәнбәт бай материал туплый, киләчәктә алар галим тарафыннан әлегәчә бастырып чыгарылмаган «Башкорт фольклоры» хрестоматиясен төзегәндә кулланыла. Ф.Урманче бәяләп үткәнчә, 1930 елның икенче яртысына галим фольклорчы-теоретик һәм практик булып формалаша [2, 45 б.]. Кулга алынуга һәм эзәрлекләүләргә карамастан, Нәкый Исәнбәт төшенкелеккә бирелми. Нәкый Исәнбәт халык әдәбияты әсәрләрен бастырып чыгаруга әзерләү эшенә керешә: «Идүкәй менән Морадым», «Идегәй» җыелма текстларны һ.б. Шулай итеп, энциклопедист галимдә халык иҗаты әсәрләрен җыю һәм бастырып чыгару буенча фәнни методика формалаша. Идеологик изү һәм цензура шартларында Алтын Урда чорындагы татар фольклоры турында бөртекләп мәгълүмат җыйган Нәкый Исәнбәтнең кыюлыгы һәм батырлыгы хөрмәткә лаек (Кар:. [24], [25]).

1939 елда Нәкый Исәнбәт җәмәгатьчелекне үзенең табышмакларны өйрәнү методлары белән таныштыра. 1941 елда «Табышмаклар» җыентыгын бастырып чыгара, ул ТАССРда гына түгел, СССР төрки тирәлегендә дә әйтеп бетергесез кызыксыну тудыра. Венгрия тюркологы Ласло Мандоки җыентыкка искиткеч яхшы бәяләмә бирә.

1939 елда татар мәгърифәтчесе «Яшь ленинчы» балалар газетасында «Фольклор бите» рубрикасын әзерләүдә катнаша. 1941 елда Нәкый Исәнбәт, цензура каршылыкларын җиңеп чыгып, «Татар халкының балалар фольклоры» җыентыгын бастырып чыгаруга ирешә. Киләчәктә фольклорчы әлеге җыентыкларны киңәйтә, кертелгән материаллар күләмен һәм аналитик мәкаләләрнең эчтәлеген арттыра. Татар фольклорчысы һәм әдәбият белгече Мөхәммәт Мәһдиев (1930–1995) карашынча, бердәнбер «Балалар фольклоры» җыентыгын бастыруга әзерләп кенә дә Нәкый Исәнбәтнең исеме илебез фольклористикасы тарихына кереп кала алыр иде [26]. Фольклорчының портфелендә уен фольклоры җыентыклары да бар: «Нәниләр шатлана» (1967), «Отканга мәкаль. Тапкырга табышмак» (1973), алар инде күптәннән укытучылар һәм ата-аналарның өстәл китабына әйләнде.

Нәкый Исәнбәтнең 4170 берәмлектән торган «Татар халык табышмаклары» җыентыгы фән дөньясында чын сенсация була. Америка галиме Н. Поппе үзенең рецензия-

сендә татар галиме тарафыннан системалаштырылган, дөньяда тиңе булмаган фольклор материалының күләме турында сокланып яза. Татар галименең тарихи шәрехләүләренә лаеклы бәя биреп, Нәкый Исәнбәт уйлап тапкан халык табышмакларын анализлау һәм классификацияләү методологиясенең уникальлеген күрсәтә һәм аны башка халыкларның фольклорында бу жанрны анализлау өчен кулланырга киңәш итә [27].

Өч томлы «Татар халык мәкальләре» җыентыгы (1959–1967) төзегән өчен Нәкый Исәнбәт Тукай премиясе лауреаты дигән исемгә лаек була. Монда кырык меңнән артык мәкаль һәм әйтемнәр җыелган, системалаштырылган һәм комментарийлар бирелгән. Фәнни җәмәгатьчелекнең бертавыштан тануынча, бу хезмәт татар филологиясенә генә түгел, ә гомуми тюркологиягә дә уникаль өлеш кертә. Нәкый Исәнбәтнең эше безнең илдә генә түгел, чит илләрдә дә яхшы бәяләмә алды. Белгечләр фикеренчә, бу бай җыентыкка кереш сүз генә дә үзенең фәнни тирәнлеге һәм әһәмияте ягыннан докторлык диссертациясенә тиңләштерелә алыр иде [22].

Нәкый Исәнбәт үз хезмәтләрендә халык иҗаты жанрларының килеп чыгышы мәсьәләләренә игътибар итә. Кагыйдә буларак, аның фәнни хезмәтләрендә әлеге материал махсус параграфка чыгарылган: Ф. Урманче галимнең бәет жанры турында төрле хезмәтләргә бирелгән комментарийларын югары бәяли [2, б. 65]. Нәкый Исәнбәт беренчеләрдән булып үз хезмәтләрендә «моң» һәм «көй» терминнарын аеру турындагы мәсьәләне күтәреп чыга. Татар фольклорчысы үз хезмәтләрендә халык календареның һәм календарь йолаларының милли үзенчәлеге турындагы мәгълүматларны системага сала. Галим фольклористикада теге яки бу жанрның тикшерелү дәрәҗәсен өйрәнүгә зур өлеш кертә, шул ук вакытта, үзебезнең генә түгел, чит ил тикшеренүчеләренең дә хезмәтләре аның игътибар үзәгендә була.

Халык дәвалау практикасын өйрәнеп, фольклорчы этноботаника һәм халык медицинасы өлкәләренә дә этно-фольклористик экскурсияләр ясый. 1922 елны бу эшнең башлангыч ноктасы дип санарга була, Нәкый Исәнбәт С. Коган белән бергә Стәрлетамакта «Башкортстанда табыла торган дару үләннәрен җыю өчен кыскача кулланма» җыентыгын чыгара. Бу өлкәдә белемнәрен системалаштыруга галимнең 1920 елда Уфада Академүзәкнең терминология комиссиясе составында эшләгән эше этәргеч була.

1930 еллар башында Нәкый Исәнбәт татар теленең аңлатмалы сүзлеге картотекасын төзергә керешә (Тулырак кар: [2, 74–86 б.], [6]) Сүзнең төзелешен һәм семантик материясен нечкә тоеп, Нәкый Исәнбәт татар теленең лексикасы артында торган гаҗәеп күп көнкүреш, тарихи, диалект һәм хәтта махсус күренешләрне дә белә. 1948 елда ул үз проектын Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына (ИЯЛИ) тәкъдим итә, аның өстендә эшне 1969 елда тәмамлый. Аның 4 томлык сүзлеге үз эченә 80 мең сүзне ала. 1950 елда галим «Татар-рус сүзлеге»н эшкәртүдә катнаша. Галим-энциклопедистның шәхси архивында без «Төрле авыру-сырхаулар, чир исемнәре» медицина сүзлеген таптык, киләчәкте фәнни әйләнешкә кертербез дип ышанабыз.

Нәкый Исәнбәт бала вакытта ук татар мифологиясе белән кызыксына. Мәдрәсәдә укыган елларда ул мөселман мифологиясе белән таныша. 1910–1920 елларда Нәкый Исәнбәт үзе дә татар-башкорт һәм мөселман мифологиясе мотивлары буенча байтак әсәрләр иҗат итә. Романтик шагыйрь үзен төрле жанрларда сынап карый: «Шүрәле» (1910), «Пәйгамбәр» (1915), «Су-сылу» (1916), «Аждаһа» (1916), «Су анасы җыры» (1922) шигырьләре; «Мәрткә киткән Гөлчирә турында» (1916) поэма; «Елан патшасы» әкияте, «Урманда» (1923) пьесасы. Әдәбият белгечләре Назыйм Ханзафаров (1937–2023) һәм Гали Арсланов билгеләп үткәнчә, ярты гасырдан соң Нәкый Исәнбәт, репертуар туплап, «үзенең үзенчәлекле фольклор театрын булдырган» [3], [8]. «Әбугалисина» драматик поэмасы (1959), «Идегәй» (1941) трагедиясе, «Түләк» (1941) либреттосы, «Хуҗа Насретдин» (1939) комедиясе, «Җирән чичән белән Карачәч сылу» (1942), «Җиде кыз» (1923) әкиятпьесасы, «Былтыр кысты» (1968), «Кырлай егете» (1968), «Бәрәзә песие Мыраубай батыр маҗаралары» (1974) һ.б. аның каләменнән төшкән.

Милли мифологияне пропагандалау өчен, Нәкый Исәнбәт төрле мөмкинлекләрдән файдаланырга тырыша. Бу темага язучы эчтәлек дәрәҗәсендә генә түгел (Шүрәле, Су анасы, Су-сылу, Амазонкалар, Җидегән йолдызлыгы мифлары), композиция һәм шигърият дәрәҗәсендә дә игътибар итә. Мәсәлән, «Идегәй» трагедиясенә ул акыллы күрәзәче Субра белән булган эпизодларны һәм

бу төшне аңлатуларны кертә. «Зифа» комедиясендә мәхәббәт сихере, еланнарны сихерләү эпизодлары бар. Балалар әкиятендә халык дәвалаучысы, еланнарны сихерләүче картның колоритлы портреты бирелә. Нәкый Исәнбәт 1942 елда үзенең революциягә кадәр үк, мөселман мифологиясе мотивлары буенча язылган пацифистик «Мәрткә киткән Гөлчирә турында» поэмасын (1916) бастырып чыгарырга җөрьәт итә.

Нәкый Исәнбәтнең архивында 1935 елда чыккан «Татар мифлары» китабының эскизлары гарәп графикасында язылган дәфтәрдә саклана, әмма бер материалда 1955 елгы чыганакка сылтамалар очрый. Бу якынча «Ни өчен ни булган, яки Утыз ялган» (1956) китабын бастырып чыгаруга әзерлек вакыты белән туры килә. Нәкый Исәнбәт мифларны 4 рубрика буенча классификацияли: 1. Исламга кадәрге чорның борынгы мифлары; 2. Бездә ислам белән бергә барлыкка килгән мифлар; 3. Сирәк очрый торган мифлар; 4. Татар мохитендә сакраль төшенчәләр. Язучының архивында табылган рецензиянең сакланып калган өзегенә караганда, «Татар мифлары» кулъязмасы рецензияләү этабын узган. Бәлки, татар язучысы массакүләм мәгълүмат чаралары өчен мәкаләләр сериясен әзерләргә теләгәндер, чөнки балалар өчен мифларны күчерү төбәк вакытлы матбугатында гына түгел, ә башкала басмаларында да уңыш казана. Нәкый Исәнбәтнең хезмәте Корней Чуковскийның (1882–1969) «Вавилонская башня и другие древние легенды» китабы белән 1968 елда булган җәнҗал аркасында басылып чыкмаган дип уйлыйбыз.

Татар мифологиясе турындагы китабын алга этәрүдә кыенлыклар белән очрашып, Нәкый Исәнбәт материалның бер өлешен «Татар халык мәкальләре» дигән өч томлык китабындагы аерым мәкальләргә авторлык комментарийларында әйләнешкә кертә, шулай ук татар мифологиясе персонажлары кергән мәкальләрне махсус параграфка җыя. «Татар теле фразеологизмнары» дигән ике томлы сүзлекне басмага әзерләгәндә дә, ул шул тактиканы куллана. 1983 елда яшь язучы Рафыйк Юныс (1941–2021) белән хат алышканда, Нәкый Исәнбәт, татарларның яшь буыны милли мифологиядә бетенләй ориентлашмый, дип борчылуын белдерә: «Бөек Тукай безне үз мифларыбыздан курыкмаска, яратырга чакырган иде». Галим, дәлил буларак, шагыйрьнең «Сабыйга» шигыреннән өземтә китерә: «Һич сине куркытмасыннар шүрәле һәм җен, убыр...» Нәкый Исәнбәт милли язучыларның, рус телендә югары белем алып, грек-рим мифологиясеннән илһам алуны өстен күрүләрен һәм үз милли мифологияләренең потенциалын бөтенләй игътибарсыз калдыруларын ачынып әйтә [28].

ТР Президенты М.Ш. Шәймиевнең 1992 елның 27 октябрендәге «Нәкый Исәнбәт истәлеген мәңгеләштерү турында»гы Указы нигезендә ТР Министрлар Кабинетының 1992 елның 28 октябрендәге Нәкый Исәнбәт истәлеген мәңгеләштерү чаралары турында 595 нче карары имзалана Г.Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм тарих институтына (җав. – директор М.З. Зәкиев), Татарстан Язучылар берлегенә (җав. – рәис Р.С. Мөхәммәдиев), Татарстан китап нәшриятына (җав. – директор Х.А. Әшрәфҗанов) язучының басылмаган әдәби мирасын үз эченә алган «Н. Исәнбәтнең әсәрләр җыентыгы»н бастырып чыгаруга әзерләү һәм бастырып чыгару, шулай ук галим-энциклопедистның иҗади мирасы буенча комиссия төзү йөкләмәсе бирелә. Нәҗибә Исәнбәт Нәкый Исәнбәтнең архивыннан 15 папка, шул исәптән «Татар мифлары» хрестоматиясенең кулъязмасын нәшриятка тапшыра. 2001 елда Йолдыз Исәнбәт «Мирас» журналында галим әзерләгән «Татар мифлары» хрестоматиясеннән берничә өзек бастырып чыгара: «Өй иясе», «Абзар иясе» мифлары һәм кереш сүз. Анда Нәкый Исәнбәт, чит ил галимнәре эшләрен дә кертеп, татар мифологиясен 1960 елга кадәр өйрәнү дәрәҗәсен билгели, терминологик база да билгеләнгән була [29]. Татарстан китап нәшриятында Нәкый Исәнбәт кулъязмаларының язмышы караңгылык белән капланган.

Нәтиҗә ясап, А. Әхмәдуллин сүзләрен китерәсе килә:

«Дөньядагы иң зур байлык ике төштә саклана. Берсе – Җир ана куенында, икенчесе – халык күңелендә. Җир куенындагы байлыкларны алырга кешегә техника ярдәмгә килә. Халык күңелендәге байлыкны табу өчен, алу өчен бернинди техника ярдәм итә алмый; әгәр дә син үзең күңеленә ачкыч таба белмәсәң, тиешле хезмәт куймасаң, халыкның мең еллар буе җыйнаган, туплаган байлыгын ала алырмын димә. Халкыбызның шундый рухи байлыгына ирешкән кешеләр бик аз, алар арасында Н. Исәнбәт аерым бер мактаулы урын тота. Гомере буе ул халык җәүһәрләрен – мәкаль һәм әйтемнәрне, мәзәк һәм

табышмакларны, җыр һәм такмазаларны бөртекләп җыеп килә. 20 нче елларда аркасына бүктәр асып, авылдан авылга йөреп башлаган бу эшен галим бүгенгә кадәр дәвам итә. Фольклор әсәрләре, галим кулына килеп кергәнче, әле эшкәртелмәгән асылташ кыяфәтендә була. Исәнбәт аларны эшкәрткәч, алар, күптөрле кырлары ачылып, чын энҗе бөртекләредәй ялтырый башлыйлар. Бу – фольклор әсәрләрен фәнни эшкәртү, системалаштыру дигән сүз, аларны тиешле рәвешкә китереп бастырып чыгару дигән сүз» [13, 3 б.].

Тикшеренү эше ФПСП-2/24 темасы кысаларында башкарылды.

**Әдәбият**


1. *Шамуков Г.* Нәкый Исәнбәт. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 53–76 б.
2. Әдип һәм галим. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 124 б.
3. *Ханзафаров Н.* Нәкый Исәнбәт драматургиясе. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 171–191 б.
4. *Бакиров М.Х.* Рецензия на научно-популярный сборник «Наки Исанбет» (Сост. М.М. Хабутдинова, Казань : Фонд «Җыен», 2021. 736 с). // Tatarica. 2023. №1 (20). С. 171–174.
5. *Госманов М.* Аксакаллар мәҗлесеннән: [Нәкый Исәнбәт тур. истәлекләр] // Казан утлары. 2010. № 11. Б. 121–135.
6. *Хабутдинова М.М.* Почему не был опубликован первый толковый словарь татарского языка Наки Исанбета? // Теория языка и межкультурная коммуникация. 2024. Выпуск 2(53). С. 291–312.
7. *Ахмадуллин А.Г.* Исанбет (Исәнбәт) Наки (Закиров Наки Сиразетдинович) // Татарская энциклопедия: в 5 т. Т. 2. Казань : Институт татарской энциклопедии АН РТ, 2005. С. 600–601.
8. *Арсланов Г.* Фольклорный театр Наки Исанбета // Гасырлар авазы. Эхо веков. 2012. №1–2. С. 251–254.
9. *Галиуллин Т.* Егерменче еллар татар шигърияте // Шигърият баскычлары. Казан : Мәгариф, 2002. Б. 72–73.
10. *Рахмани Р., Миңнуллина Ф.* Нәкый Исәнбәт // Татар әдәбияты тарихы : 8 т. – 5 т. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2014. 374–392 б.
11. *Хәбетдинова М.М.* «Чорлар рухание» // Казан утлары. 2020. №1. С.150–162.
12. *Хаплехамитов Р.* Первые годы постсталинского периода в Татарстане: взаимоотношения власти и творческой интеллигенции // Известия Самарского научного центра Российской академии наук. Т. 10, №1, 2008. С. 136–140.
13. Нәкый Исәнбәт: фәнни-популяр җыентык / Төз. М.М. Хәбетдинова. – Казан: Җыен, 2021. 736 б.
14. *Исәнбәт Н.* Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: 3 томда / Нәкый Исәнбәт. –1 т. – Казан: Татар. кит. нәшер., 2010. 622 с.
15. *Исәнбәт Н.* Казан артына беренче сәяхәтем: «Оры аккан» // Tatarica. 2023. № 2 (21). 76–100 б.
16. *Исәнбәт Н.* «Коңгыр бога» көе: тарихи тамырлары һәм поэтикасы төрки халыклар мәдәнияте контекстында // Tatarica. 2023. № 1 (20). 32–43 б.
17. Хәбетдинова М., Хәбибуллин Ф. Нәкый Исәнбәт чичәнлек сәнгате турында / М. Хәбетдинова, Ф. Хәбибуллин // Tatarica. 2021. №17 (2). 119–140 б
18. Сүз табучы сукыр Фәррах әңгәмәләре: [Н.Исәнбәтнең «Фәррах җырлары турында» дигән мәкаләсе белән]. Уфа: «Башкнига» һәм Башнаркомпрос нәшере, 1928. 32 б.
19. Әйдә җырлыйк!: (Революция чорында халык җырлары) / Җыючысы Н.Исәнбәт. Казан: Татар. дәүл. нәшр., 1928. 40 б.
20. *Хабутдинова М.М.* Наки Исанбет как автор и читатель журнала сатиры и юмора «Чаян« // Modern Humanities Success/Успехи гуманитарных наук. 2022. №9. С. 12–19.
21. *Хабутдинова М.М.* Наки Исанбет как автор журнала «SƏNƏK» («Вилы») // Modern Humanities Success/Успехи гуманитарных наук. 2022. №9. С. 52–59.
22. *Мустафин Р.* Наки Исанбету 75 лет: сценарий радиопередачи // Архив писателя Наки Исанбета. 1974. Машинопись. 3 л.
23. *Исанбет Ю.* Статья Наки Исанбета «На путях становления татарской музыки (1923)» как источник научного комментирования // Tatarica. 2021. №2 (17) 141–168 б.
24. *Хабутдинова М.М.* Вклад Наки Исанбета в изучение Золотой Орды // Золотоордынское обозрение. 2023. №1 (11). С. 181–201.
25. *Замалетдинов Р., Хабутдинова М.* Творческая история комедии Наки Исанбета «Рыжий чичян и Черноволосая красавица» // Золотоордынское обозрение. 2023. Vol.11, Is.4. С. 934–956.
26. *Мәһдиев М.* Үтте айлар, үтте еллар, Син сазыңны уйнадың... // Яшь ленинчы. 1979. 2 б.
27. (1971) *Poppe N.* Татар халык табышмаклары, 1970. // Central Asiatic journal: international periodical for the languages, literature, history and archaeology of Central Asia (Wiesbaden), vol. XV, №3.
28. Нәкый Исәнбәтнең Рафыйк Юнусовка язган хаты / Н.Исәнбәтнең архивы. Казан. 983. 20 сентябрь. Машинопись. 7 л.
29. *Исәнбәт Н.* Татар мифлары // Мирас. 2001. №3. 17–28 б.